КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 март г.Казань № 249

Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килә торган туризм өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килә торган туризм өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 36 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин